**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
(IV чакырылыш)

егерме өченче утырыш
**КАРАРЫ**

14 декабрь 2022 ел **№ 162** Теләче ав.

Теләче муниципаль районы Советының 2012 елның
12 апрелендәге 97 номерлы «Өч һәм аннан күбрәк
баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү
турында карар кабул итү тәртибе хакында»
карарына үзгәрешләр кертү турында

Теләче районы прокуратурасының 2022 елның 1 ноябрендәге 02-0801 номерлы протестын карап, «Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм 32.1 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 25 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 2 ноябрендәге 76 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Теләче муниципаль районы Советы **карар итте:**

1. Теләче муниципаль районы Советының 2012 елның 12 апрелендәге 97 номерлы «Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карар кабул итү тәртибе хакында» карарына (10.08.2012 № 116, 21.11.2018 № 152, 28.03.2019 № 170, 21.08.2019 № 188 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
- Әлеге карар белән расланган өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләрен бирү турында карар кабул итү Тәртибенә:
А) 3 пунктта "бакчачылык, яшелчәчелек, йә аларга җир кишәрлекләрен тапшыруга" сүзләрен "бакчачылык яисә үз ихтыяҗлары өчен яшелчәчелек йә аларга җир кишәрлеген бирүгә" сүзләренә алмаштырырга;
Б) 7 пунктта "бакчачылык, яшелчәчелек" сүзләрен «бакчачылык яисә үз ихтыяҗлары өчен яшелчәчелек" сүзләренә алмаштырырга;
В) 14 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:
«14. Шәхси торак төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык (йорт янындагы җир кишәрлеге), бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару өчен җир кишәрлеге алу хокукына ия гражданнар исемлекләренә кертү турында карар кабул итү өчен мөрәҗәгать итүче гариза биргән көннән 14 көннән дә соңга калмыйча түбәндәге документлар тапшыра:
1) мөрәҗәгать итүченең паспорты;
2) башка ата-анасы паспорты (әгәр ата-ана никахта торса йә никахта тормаса, бергә яшәгән очракта);

3) балалар туу турында таныклык, шулай ук үндүрт яшькә җиткән балалар паспортлары;
4) баланы уллыкка алуны билгеләү турында суд карары (баланың туу турындагы таныклыкта уллыкка алучылар ата-ана буларак язылган очраклардан тыш);
5) опекун яисә попечитель билгеләү турында опека һәм попечительлек органы акты (опека яисә попечительлек билгеләнгән очракта);
6) опека яисә попечительлекне гамәлгә ашыру турында шартнамә (шартнамә буенча опека яисә попечительлек гамәлгә ашырылган очракта);
7) никахлашу турында таныклык (ата-ана никахта торган очракта);
8) мөрәҗәгать итүченең социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак бинада мохтаҗ буларак исәптә торуын раслый торган документ;
9) җир кишәрлеге бирү турында гариза биргән көнгә кадәрге биш ел дәвамында мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү фактын билгеләү турында суд карары (мөрәҗәгать итүченең паспортында җир кишәрлеге бирү турында гариза бирелгән көнгә кадәрге биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлү турында тамга булмаган очракта).
Әлеге пунктның 8 пунктчасында күрсәтелгән документ, әгәр мөрәҗәгать итүче аны үз инициативасы белән тапшырмаган булса, җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан мөстәкыйль рәвештә соратып алына.»;
Г) ә 20 пунктта «бакчачылык яисә яшелчәчелек» сүзләрен «үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә  яшелчәчелек» сүзләренә алмаштырырга;
Д) 22 пунктның икенче абзацында «бакчачылык яисә яшелчәчелек» сүзләрен «үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек» сүзләренә алмаштырырга;
Е) 31 пунктта:
- 2) пунктчаны түбәндәге эчтәлекле д өлеше белән тулыландырырга:
«д) социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәптән төшерү;»;
- 4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4) җир кишәрлеген сайлау процедурасында гражданнарның өч тапкыр җир кишәрлеген сайлаудан баш тартуы, яисә җир кишәрлеген сайлау процедурасына гражданнарның өч тапкыр килмәве, йә гражданнарның җир кишәрлеген сайлау процедурасында җир кишәрлеген сайлаудан баш тарту һәм аларның җир кишәрлеген сайлау процедурасына килмәү очраклары саны өч тапкырга тигез;».
2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль
районы башлыгы　　　　　　　　　　　　　　　　Н.Н. Хаҗипов